# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛЛӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ LXVI УТЫРЫШЫ

## КАРАР № 91

**Мәллә-Тамак авылы** **17 нче июнь 2025 ел**

**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мәллә-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының бишенче чакырылыш Мәллә-Тамак авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Авыл утлары» («Сельские огни») газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

Мәллә-Тамак авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Насифуллина